ГЛАВА АБСАЛЯМОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.2,
с.Абсалямово, 423957

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшьләр урамы, 2 йорт,
Әбсәләм авылы, 423957

Тел.:(85593) 4-26-79, факс:4-26-79, e-mail: Absal..Utz@tatar. ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 4** **15 декабря 2020 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсе торак пунктында 2021 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында"гы нигезләмәнең 4 бүлегенең 4.4 пунктчасы нигезендә Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Әбсәләм авыл җирлеге, Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсе, Тынычлык урамы, 3 нче йорт янында 2020 елның 25 декабрендә 13 сәгат 00 минутта 2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсе торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

2.1. 2020 елның 21 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге, Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында"гы 2 санлы халык җыены карарын гамәлдән чыгару белән килешәсезме?

2.2. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге, Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 2021 елда 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым (бер тапкыр түләүләр) акчаларын кертүгә

һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әпсәләм авыл җирлегенең Әпсәләм тимер юл разъезды бистәсе торак пунктында Тынычлык урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитеты гражданнар җыенын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 5 көн эчендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

5. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән көннән үз көченә керә.

Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В. Кубашева